**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2016 елның 25 мартындагы ПУ-282 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 июнендәге ПУ-538 номерлы, 2016 елның 29 сентябрендәге ПУ-884 номерлы, 2016 елның 20 декабрендәге ПУ-1151 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы ПУ-259 номерлы, 2017 елның 24 июнендәге ПУ-537 номерлы, 2017 елның 30 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1177 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы ПУ-272 номерлы, 2018 елның 23 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2018 елның 25 сентябрендәге ПУ-688 номерлы, 2018 елның 19 ноябрендәге ПУ-779 номерлы, 2019 елның 4 февралендәге ПУ-62 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2019 елның 27 июнендәге ПУ-371 номерлы, 2019 елның 27 сентябрендәге ПУ-577 номерлы, 2020 елның 11 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы, 2020 елның 31 мартындагы ПУ-220 номерлы, 2020 елның 15 июлендәге ПУ-403 номерлы, 2020 елның 30 сентябрендәге ПУ-639 номерлы, 2020 елның 28 декабрендәге ПУ-887 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2021 елның 14 сентябрендәге ПУ-710 номерлы, 2021 елның 30 сентябрендәге ПУ-770 номерлы, 2022 елның 31 мартындагы ПУ-230 номерлы, 2022 елның 30 сентябрендәге ПУ-690 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге ПУ-921 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 31 мартындагы 193 номерлы, 2023 елның 25 маендагы 331 номерлы, 2023 елның 30 сентябрендәге 689 номерлы, 2024 елның 30 мартындагы 228 номерлы, 2024 елның 20 июнендәге 475 номерлы һәм 2024 елның 28 сентябрендәге 756 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составыннан чыгарырга:

Әгерҗе муниципаль районы буенча В.А. Гусаровны;

Актаныш муниципаль районы буенча А.М. Фазыловны;
Буа муниципаль районы буенча С.В. Сысоевны;
Югары Ослан муниципаль районы буенча А.А. Бортниковны;
Лаеш муниципаль районы буенча Е.В. Коробованы;
Лениногорск муниципаль районы буенча З.Г. Михайлованы;
Мамадыш муниципаль районы буенча Р.З. Никифоровны;
Менделеевск муниципаль районы буенча М.М. Зариповны;
Саба муниципаль районы буенча Л.И. Шәйдуллинны;
Сарман муниципаль районы буенча Г.Я. Идрисованы;
Чирмешән муниципаль районы буенча Л.В. Мөэсинованы;
б) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары буенча Мөхәммәтгәрәева Ирина Дамир кызын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесен;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вахитов һәм Идел буе районнары буенча Глухарева Елена Владимировнаны – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесен;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Совет районы буенча Әхмәтшина Талия Габделәхәт кызын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесен;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Үзәк һәм Автозавод районнары буенча Зарипов Марат Мисхәт улын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Чаллы шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесен;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Комсомол районы буенча Силаичева Ольга Александровнаны – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Чаллы шәһәрендәге җәмәгать ярдәмчесен;

Әгерҗе муниципаль районы буенча, хәрби хезмәткә чакырылучы гражданнарны медицина буенча таныклау эшенә җитәкчелек итүче табиб итеп раслап, Катаева Ангелина Евгеньевнаны, Әгерҗе үзәк район хастаханәсе табиб-стоматологын;

Актаныш муниципаль районы буенча Хөҗҗәтов Илназ Наил улын – «ЯШЬ АРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Актаныш районы буенча җирле бүлекчәсе штаб башлыгын;

Буа муниципаль районы буенча Рәхмәтуллин Ранис Миңназыйм улын – «ЯШЬ АРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең Буа районы буенча җирле бүлекчәсе штаб башлыгын;

Югары Ослан муниципаль районы буенча Сакин Анатолий Викторовичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Зәй муниципаль районы буенча Биканов Игорь Александровичны – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Зәй муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесен;

Кама Тамагы муниципаль районы буенча Габидуллин Газинур Әүхәт улын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Кама Тамагы муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесен;

Лаеш муниципаль районы буенча Кәримова Людмила Михайловнаны – Лаеш үзәк район хастаханәсе баш табибы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Лениногорск муниципаль районы буенча, комиссия рәисе итеп раслап, Гыйрфанов Марат Нил улын – Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен;

Мамадыш муниципаль районы буенча, комиссия рәисе итеп раслап, Гарипов Рәшит Мөхәммәтдин улын – Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен;

Түбән Кама муниципаль районы буенча Шәвәлиева Эльмира Мөнәвир кызын – Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе консультация-диагностика поликлиникасының 1 номерлы тар белгечләр бүлекчәсе шәфкать туташын;

Балык Бистәсе муниципаль районы буенча Әхәтов Халидин Самат улын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесен;

Саба муниципаль районы буенча Миңнеханов Ленар Мөнир улын – «Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Саба районы буенча бүлеге әйдәүче инспекторын;

Сарман муниципаль районы буенча Исмәгыйлева Гөлназ Тәлгать кызын – Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгын;

Чирмешән муниципаль районы буенча Вафина Гөлназ Вәлиҗан кызын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең Чирмешән муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесен;

в) Баулы муниципаль районы буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе әгъзасы С.Р. Шәрәпованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Баулы районы буенча бүлеге башлыгы»;

г) Зеленодольск муниципаль районы буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе әгъзасы Г.К. Әхмәтҗанованың фамилиясен, исемен, атасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Насыйбуллина Гөлназ Камбәр кызы»;

д) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре резерв составыннан чыгарырга:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Киров һәм Мәскәү районнары буенча А.В. Михеевны;

Югары Ослан муниципаль районы буенча М.М. Черменскийны, Н.П. Каинаны, Е.В. Кирилловны;

Лениногорск муниципаль районы буенча Г.Х. Вагыйзованы;

Нурлат муниципаль районы буенча И.Г. Зәйниевны;

Питрәч муниципаль районы буенча Р.Р. Даниловaны;

Саба муниципаль районы буенча Л.М. Миңнехановны;

Чистай муниципаль районы буенча О.В. Мангуловaны;

Ютазы муниципаль районы буенча С.Х. Бордачеваны;

е) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре резерв составына кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Киров һәм Мәскәү районнары буенча Варламов Марат Михайловичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 5 номерлы «Мәскәү» полиция бүлеге башлыгын;

Югары Ослан муниципаль районы буенча: комиссия рәисе итеп раслап, Алеева Ирина Павловнаны – Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын, Зайцева Олеся Әхәтгилди кызын – «Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Югары Ослан районы буенча бүлеге әйдәүче инспекторын, Козлов Константин Олеговичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге җәмәгать тәртибен саклау полициясе башлыгы урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Лениногорск муниципаль районы буенча, комиссия рәисе итеп раслап, Михайлова Зөлфия Габделхәмит кызын – «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарын;

Нурлат муниципаль районы буенча Төхвәтуллин Ринат Мансур улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы урынбасары – балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсе башлыгын;

Питрәч муниципаль районы буенча Иванова Ләйсән Хәмит кызын – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге методистын;

Чистай муниципаль районы буенча Тугашова Любовь Анатольевнаны – «Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Чистай районы буенча бүлеге башлыгы урынбасарын;

Ютазы муниципаль районы буенча Галимова Гөлназ Марсель кызын – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлегенең тәрбия эше буенча методистын.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 28 декабрь
№ 1037